КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 октябрь г.Казань № 1341

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2015 ел, 12 март, 148 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 7 ноябрь, 820 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктында татар текстында «башкарма хакимият» сүзләре алдына «республика» сүзен өстәргә

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» 2015 ел, 20 март, 177 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1503 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эшенең бертип регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 1 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның 1 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 23 март, 155 нче карары белән расланган Аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү тәртибенә, 2 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 24 май, 338 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенә төзелгән (реконструкцияләнгән) күчемсез мөлкәт объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итү регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» сүзләренә алмаштырырга, «2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы» сүзләрен «2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы» сүзләренә, «Россия Төзелеш министрлыгының 117/пр номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Төзелеш министрлыгының 446/пр номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта «117» саннарын «446» саннарына алмаштырырга;

2.3 пунктның дүртенче абзацында «тапшырыла» сүзе алдына «яки оператив идарәгә» сүзләрен өстәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өченче зат хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 ел, 25 май,

353 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 114 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 882 нче; 2021 ел, 9 июнь, 443 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1503 нче; 2023 ел, 20 апрель, 510 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өченче зат хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә, 3 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатларында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2018 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 август, 746 нчы; 2021 ел, 25 август, 779 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатла-рында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 5 пунктчасында «федераль башкарма хакимият органы» сүзләрен «федераль башкарма хакимият органы вәкиле» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары, әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 3 – 5 пунктчаларында күрсәтелгән федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органыннан рәсми сорау кергән көннән 15 көннән дә соңга калмыйча, Комиссия эшчәнлегендә катнашу өчен вәкилләр кандидатураларын Татарстан Республикасы җирле үзидарә органына җибәрә.».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчемсез мөлкәт объектларының кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен дәгъвалау турында административ эшләр буенча суд чыгымнарын түләтү турындагы суд актларында булган таләпләрне үтәү вәкаләтләрен

гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 26 апрель, 284 нче карарына, 1 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин